ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**08.12.2022**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 3389**

Зеленодольск районы Башкарма комитетының 2022 елның 13 маендагы 1142 номерлы карары белән расланган, автомобиль юлларының торышы турында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларга мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 августындагы «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 1415 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ**:

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 13 маендагы 1142 номерлы карары белән расланган, автомобиль юлларының торышы турында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларга мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба - административ регламент), үзгәрешләр кертергә:

1.1. административ регламентның 3.3.2.1 пунктының унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.2.1. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан рәсми мөрәҗәгатьнең электрон формасында һәр юлын тутыру процессында формалаштырылган рәсми мөрәҗәгатьне формаль-логик тикшерү, орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, Бердәм порталда автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан рәсми мөрәҗәгатьнең электрон формасында дөрес тутырылмаган юллары ачыкланганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры рәсми мөрәҗәгатьнең электрон формасында мәгълүмати хәбәр аша җиткерелә.».

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru ) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин